ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2016 Балык Бистәсе штп. № 14пи

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатларында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «СанПин 2.4.5409-08 раслау турында» 2008 елның 23 июлендәге №45 карары , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2015 ел, 23 сентябрь, 698 нче, «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 ел, 17 декабрь, 721 нче карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы барлык укучыларны (алга таба-муниципаль гомуми белем бирү оешмалары) кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга.

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыру чыгымнарын финанслауга юнәлдерергә:

- 2016 елның 1 гыйнварыннан бер укучыга бер көнгә 6 сум 50 тиен күләмендә туклану өчен субсидияләр;

-озынайтылган көн төркемнәрендә түләүсез яки ташламалы туклануга акча (озайтылган көн белән муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укучыларның гомуми составына карата 25% ка кадәр), шулардан 10% ка кадәр-тулысынча, 15% ка кадәр-туклану өчен түләү күләменең яртысына кадәр);

-муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш акчалары;

- әти-әниләрнең ирекле взнослары.

3. 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәм үз составында 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләрне түләүсез туклану белән тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының әлеге карарда күрсәтелгән максатларга чыгымнарының расланган сметалары чикләрендә җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабына финанс чараларын үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5.Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларның азык-төлек матдәләренә һәм энергияләренә булган физик ихтыяҗларына туры китереп кайнар аш белән тәэмин итүне, тәүлеклеклек туклану рационының калориясен бүлүне оештырырга;

- ярдәмче хуҗалыклардан һәм мәктәп яны кишәрлекләреннән кергән табышлардан файдаланып, аз керемле гаиләләрдән булган балаларны туклануны оештыруны күздә тотарга ;

- балалар өчен кайнар ашка ата-аналар взносы җыю-көнгә 25 сум, төшке ашка-40 сум, балансны туклану белән тәэмин итү өчен-40 сум, озынайтылган көн төркемендәге ата-аналар взносларын җыю-көненә 20 сум.;

- укучыларны тукландыруны оештыру өчен ярдәмче хуҗалыклардан керемнәр һәм мәктәп яны участокларында җыелган санитария-гигиена нормаларына туры килә торган уңыштан файдаланырга кирәк.

6. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасарына (И.Л. Миличихин) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының ашханәләрендә санитар-гигиена нормаларының үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

9.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин